| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

27.12.2018 г.Казань № 1150

Боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 06 февралендә 5423 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2012 елның 25 июлендәге 592 номерлы боерыгы белән расланган Билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга, тикшерүләр үткәрү, мәҗбүри үтәлергә тиешле күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр тутыру хокукы белән, күзәтчелек һәм контрольлекне гамәлгә ашыру буенча дәүләт функцияләрен үтәү буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы административ регламентына үзгәреш кертү турында

Б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга, тикшерүләр үткәрү, мәҗбүри үтәлергә тиешле күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр тутыру хокукы белән, күзәтчелек һәм контрольлекне гамәлгә ашыру буенча дәүләт функцияләрен үтәү буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы административ регламентын раслау турында» 2012 елның 25 июлендәге 592 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 11.01.2013 № 5, 25.09.2014 № 518, 02.06.2015 № 366, 02.07.2016 № 377, 02.05.2017 №269 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга, тикшерүләр үткәрү, мәҗбүри үтәлергә тиешле күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр тутыру хокукы белән, күзәтчелек һәм контрольлекне гамәлгә ашыру буенча дәүләт

функцияләрен үтәү буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы административ регламентына, аны яңа редакциядә бәян итеп (кушымтада бирелә), үзгәреш кертергә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 25.07.2012 № 592 боерыгы белән (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 27.12.2018 № 1150 боерыгы редакциясендә) расланды

# БИЛГЕЛӘНГӘН КВОТА ЧИКЛӘРЕНДӘ ИНВАЛИДЛАРНЫ ЭШКӘ АЛУГА, ТИКШЕРҮЛӘР ҮТКӘРҮ, МӘҖБҮРИ ҮТӘЛЕРГӘ ТИЕШЛЕ КҮРСӘТМӘЛӘР БИРҮ ҺӘМ БЕРКЕТМӘЛӘР ТУТЫРУ ХОКУКЫ БЕЛӘН, КҮЗӘТЧЕЛЕК ҺӘМ КОНТРОЛЬЛЕКНЕ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯЛӘРЕН ҮТӘҮ БУЕНЧА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ АДМИНИСТРАТИВ РЕГЛАМЕНТЫ

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

### ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕНЕҢ АТАЛЫШЫ

1.1. Әлеге Административ регламент билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга, тикшерүләр үткәрү, мәҗбүри үтәлергә тиешле күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр тутыру хокукы белән, күзәтчелекне һәм контрольлекне (алга таба – күзәтчелек һәм контроль) гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) административ процедуралары (гамәлләре) срокларын һәм эзлеклелеген билгели.

Дәүләт функциясенең аталышы: билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга, тикшерүләр үткәрү, мәҗбүри үтәлергә тиешле күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр тутыру хокукы белән, күзәтчелекне һәм контрольлекне гамәлгә ашыру (алга таба – дәүләт функциясе).

### КҮЗӘТЧЕЛЕКНЕ ҺӘМ КОНТРОЛЬНЕ ТУРЫДАН-ТУРЫ БАШКАРУЧЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ХАКИМИЯТЕ БАШКАРМА ОРГАНЫНЫҢ ИСЕМЕ

1.2. Күзәтчелекне һәм контрольне гамәлгә ашыручы дәүләт хакимияте башкарма органы булып Министрлык тора.

Күзәтчелекне һәм контрольне турыдан-туры башкаручылар булып Министрлыкның социаль яклanмаган категорияләр өчен эш урыннары булдыру бүлеге, территориаль социаль яклау органнары – Министрлыкның социаль яклау идарәләре (бүлекләре) (алга таба – социаль яклау идарәләре (бүлекләре)),

Министрлыкның Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры (алга таба – министр), халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге мәсьәләләрнең кураторы булган Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары (алга таба – министр урынбасары) боерыгы (күрсәтмәсе) белән тикшерү уздыруга вәкаләт бирелгән дәүләт граждан хезмәткәрләре (алга таба – тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар) тора.

«Тикшерүләрнең бердәм реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – тикшерүләрнең бердәм реестры), «Татарстан Республикасының йогынты ясау актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына тиешле мәгълүматны кертү билгеләнгән тәртиптә Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан башкарыла.

Дәүләт функциясен үтәгәндә Министрлык Татарстан Республикасы прокуратурасы органнары (алга таба – прокуратура органнары), Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре, экспертлар һәм эксперт оешмалары, юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән үзара хезмәттәшлек итә.

## КҮЗӘТЧЕЛЕКНЕҢ ҺӘМ КОНТРОЛЬНЕҢ ҮТӘЛҮЕН ҖАЙГА САЛА ТОРГАН НОРМАТИВ ХОКУКЫЙ АКТЛАР ИСЕМЛЕГЕ

1.3. Күзәтчелек һәм контроль түбәндәгеләргә нигезләнеп гамәлгә ашырыла:

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы (алга таба – Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, № 1, 1 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, № 1, 3 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законы (алга таба – 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законы) (Ведомости Съезда народных депутатов РСФСР и Верховного Совета РСФСР, 1991, № 18, 565 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә гражданнарны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 181-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 27.11.1995, № 48, 4563 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 59-ФЗ номерлы федераль закон)(Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 19, 2060 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре турында һәм мәгълүмат яклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы федераль закон (Россия

Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 31, 3448 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 294-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2008, № 52, 6249 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – «Электрон имза турында» федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында» 2014 елның 29 декабрендәге 473-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 473-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, № 1, 26 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 489 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 28, 3706 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләрнең бердәм реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре турында» 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 415 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, № 19, 2825 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнар тарафыннан алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре резидентларына карата уздырыла торган уртак планлы тикшерүләр турында» 2015 елның 22 октябрендәге 1132 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1132 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, № 44, 6127 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан документларга һәм (яисә) мәгълүматларга, шул исәптән электрон рәвештә, шушы документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмаларга гарызнамәләр җибәрү һәм аларны түләүсез нигездә алу турында» 2016 елның 18 апрелендәге 323 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 323 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016 № 17, 2418 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Зарури таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтүләр төзү һәм җибәрү, юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан мондый кисәтүләргә ризасызлыклар бирү һәм аларны карап тикшерү, мондый кисәтүне үтәү турында хәбәр итү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 10

февралендәге 166 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 166 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2017, № 8, 1239 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең Тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында шушы документлар һәм (яки) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалардан сорала һәм алына торган документлар һәм (яки) мәгълүматлар исемлеген раслау турында 2016 елның 19 апрелендәге 724-р номерлы боерыгы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016, № 18, 2647 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру хакында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы (алга таба – Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы) (Российская газета, 2009, 14 май, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга, тикшерүләр үткәрү, мәҗбүри үтәлергә тиешле күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр тутыру хокукы белән, күзәтчелек һәм контрольлек дәүләт функциясенең федераль дәүләт стандартын раслау турында» 2013 елның 30 апрелендәге 181н номерлы боерыгы (Российская газета, 2013, 14 август, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Россия Федерациясе территориясендә, Ерак Көнчыгыш федераль округы территориясеннән тыш, оештырылган алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларына карата дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль органнар тарафыннан планнан тыш тикшерүләр уздыруны килештерү тәртибен раслау турында» 2016 елның 19 декабрендәге 817 номерлы боерыгы (алга таба – Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 817 номерлы боерыгы) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2017, 21 март, бастырып чыгару номеры: 0001201703210041);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Медик-социаль экспертиза буенча дәүләт учреждениеләреннән бирелә торган инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасын, инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру тәртибен һәм аларның формаларын раслау турында» 2017 елның 13 июнендәге 486н номерлы боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru, 2017, 1 август, бастырып чыгару номеры: 0001201708010058);

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Республика Татарстан, 2003, 17 май, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2006 елның 19 июнендәге 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Республика Татарстан, 2006, 27 июнь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннарын квоталау һәм резервлау турында» 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 60-ТРЗ номерлы ТР Законы)(Республика Татарстан, 2006, 28 июль, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органы турында бертип нигезләмә раслау турында» 2006 елның 3 апрелендәге 144 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, № 14, 2006, 0365 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек башкаручы эш бирүчеләргә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен хезмәт урыннарын квоталау тәртибе турында нигезләмә раслау хакында» 2007 елның 4 маендагы 170 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек башкаручы эш бирүчеләргә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен хезмәт урыннарын квоталау тәртибе турында нигезләмә (алга таба – 170 номерлы ТР МК карары, Нигезләмә) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2007, № 19, 0673 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 15 августындагы 388 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2007, № 33, 1178 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының йогынты ясау актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2013 елның 23 августындагы 593 номерлы карары (алга таба – 593 номерлы ТР Министрлар Кабинеты карары)(«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2013, № 65, 2059 ст.);

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән

тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген раслау турында» 2007 елның 12 ноябрендәге 346 номерлы боерыгы (алга таба – Министрлыкның 2007 елныд 12 ноябрендәге 346 номерлы боерыгы) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2007, № 46, 1833 ст.).

## КҮЗӘТЧЕЛЕК ҺӘМ КОНТРОЛЬ ОБЪЕКТЛАРЫ

1.4. Күзәтчелек һәм контроль объектлары булып оешу-хокук формасына һәм милекчелек формасына бәйсез рәвештә, Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашыручы, шул исәптән 473-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентлары булып торучы, хезмәткәрләренең уртача исемлек саны кимендә 35 кешедән торган һәм үзләренә карата Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә инвалидларны эшкә алу өчен квота билгеләнгән юридик затлар, шәхси эшкуарлар (алга таба – тиешенчә, юридик затлар, шәхси эшкуарлар) тора, дәүләт хакимияте органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарыннан, инвалидларның иҗтимагый оешмаларыннан һәм алар оештырган оешмалардан, шул исәптән устав (тупланма) капиталы инвалидларның иҗтимагый оешмасы кертеменнән торучы хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, шулай ук үзләренә карата законнарда билгеләнгән тәртиптә аларның бетерелүе турында карар кабул ителгән оешмалардан тыш.

## КҮЗӘТЧЕЛЕК ҺӘМ КОНТРОЛЬ ПРЕДМЕТЫ

1.5. Күзәтчелек һәм контроль предметы булып эш бирүчеләрнең билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алу буенча бурычларны үтәү буенча Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләрне үтәве, шулай ук Министрлыкның вазыйфаи заты күрсәтмәләрен үтәве, гражданнарның гомеренә һәм сәламәтлегенә зыян килүне булдырмау, мондый зыян килү нәтиҗәләрен бетерү буенча чаралар уздыруы тора.

## КҮЗӘТЧЕЛЕКНЕ ҺӘМ КОНТРОЛЬНЕ ГАМӘЛГӘ АШЫРГАНДА МИНИСТРЛЫК ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРЫНЫҢ ХОКУКЛАРЫ, БУРЫЧЛАРЫ ҺӘМ АЛАР ӨЧЕН ЧИКЛӘМӘЛӘР

1.6. Тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар тикшерү уздырылганда түбәндәгеләргә хокуклы була:

1) урынга чыгып тикшерү уздырылганда хезмәт таныклыгы күрсәтелгәндә һәм юридик зат җитәкчесенә, шәхси эшкуарга министрның (министр урынбасарының) тикшерү уздыру турында боерыгы (күрсәтмәсе) күчермәсе күрсәтелгәндә тикшерелә торган юридик затка, шәхси эшкуарга барырга;

2) планлы урынга чыгып тикшерү уздыруга үзенә карата тикшерү уздырыла торган оешма белән граждани-хокукый һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаучы экспертларны, эксперт оешмаларын җәлеп итәргә;

3) түләүсез нигездә, шул исәптән электрон рәвештә, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән исемлеккә кертелгән документларны һәм (яки) мәгълүматларны шушы документлар һәм (яки) мәгълүматлар белән эш итүче дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән чорларда һәм тәртиптә соратырга һәм алырга;

4) тикшерү уздыру турында күрсәтмә яки боерык кабул ителгәннән соң юридик заттан, шәхси эшкуардан кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматны сорарга; урынга чыгып тикшерү уздырылганда юридик заттан, шәхси эшкуардан тикшерүнең максатларына, бурычларына һәм предметына бәйле документларны алырга, әгәр мондый документлар һәм (яки) мәгълүмат алар тарафыннан документар тикшерү барышында тапшырылмаган булса.

1.7. Тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар тикшерү уздырылганда түбәндәгеләрне бурычлы була:

1) зарури таләпләр бозылуны кисәтү, ачыклау һәм чикләү буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне үз вакытында һәм тулы дәрәҗәдә башкарырга;

2) Россия Федерациясе законнарын, үзләренә карата тикшерү уздырылучы юридик затның, шәхси эшкуарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен сакларга;

3) министрның, министр урынбасарының тикшерү уздыру турында күрсәтмәсенә яки боерыгына ярашлы итеп, аның билгеләнүе сәбәпле тикшерү уздырырга;

4) тикшерүне бары тик хезмәт вазыйфаларын үтәү вакытында гына үткәрергә, урынга чыгып тикшерүне бары тик хезмәт таныкларын, министр, министр урынбасары күрсәтмәсенең яки боерыгының күчермәсен һәм, 294-ФЗ номерлы федераль законның 10 статьясының 5 өлешендә каралган очракта, тикшерү уздыруның прокуратура органы белән килешенгән булуы турында документ күчермәсен күрсәткәндә генә үткәрергә;

5) юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерүне үткәргәндә катнашуына һәм тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләрдә аңлатмалар бирүенә каршы килмәскә;

6) тикшерүне үткәргәндә катнашучы юридик зат җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү предметына кагыла торган мәгълүматларны һәм документларны бирергә;

7) юридик зат җитәкчесен, бүтән вазыйфаи затын яки вәкаләтле вәкилен, шәхси эшкуарны, аның вәкаләтле вәкилен тикшерү нәтиҗәләре белән, шул исәптән тикшерү акты белән, таныштырырга;

8) юридик зат җитәкчесен, бүтән вазыйфаи затын яисә вәкаләтле вәкилен,

шәхси эшкуарны, аның вәкаләтле вәкилен ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән таныштырырга;

9) ачыкланган бозулар буенча күрелә торган чараларны билгеләгәндә күрсәтелгән чараларның бозуларның авырлыгына, аларның кешеләрнең гомере, сәламәтлеге, хайваннар, үсемлекләр, әйләнә-тирә мохит, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре), дәүләт иминлеге өчен, табигый һәм техноген холыклы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүе өчен потенциаль куркыныч булуына туры килүен исәпкә алырга, шулай ук гражданнарның, шул исәптән шәхси эшкуарларның, юридик затларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре нигезсез рәвештә чикләнүенә юл куймаска;

10) юридик зат, шәхси эшкуар шикаять белдергәндә үз гамәлләренең нигезле булуын Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә дәлилләргә;

11) тикшерү үткәрүнең 294-ФЗ номерлы федераль законда билгеләнгән вакытларын сакларга;

12) юридик заттан, шәхси эшкуардан Россия Федерациясе законнарында тапшырылуы каралмаган документларны һәм бүтән белешмәләрне таләп итмәскә;

13) урынга чыгып тикшерү үткәрә башлар алдыннан юридик зат җитәкчесенең, бүтән вазыйфаи затының яисә вәкаләтле вәкиленең, шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең гозере буенча аларны әлеге Административ регламент нигезләмәләре белән таныштырырга;

14) юридик затта, шәхси эшкуарда булган очракта, үткәрелгән тикшерү турында тикшерүләрне исәпкә алу журналында язу теркәргә.

1.8. Тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар тикшерү уздырылганда түбәндәгеләргә хокуклы түгел:

1) әгәр мондый таләпләр Министрлык вәкаләтләренә карамаса, зарури таләпләр үтәлешен тикшерергә;

2) СССР һәм РСФСР башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен, шулай ук үтәлеше Россия Федерациясе законнарында каралмаган норматив документларның таләпләре үтәлешен тикшерергә;

3) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылмаган хокукый актларда билгеләнгән зарури таләпләр үтәлешен тикшерергә;

4) тикшерү уздырганда юридик зат җитәкчесе, бүтән вазыйфаи заты яисә аның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле булмый торган очракта, планлы яисә урынга чыгып планнан тыш тикшерүне гамәлгә ашырырга, мондый тикшерү 294-ФЗ номерлы федераль законның 10 статьясының 2 өлешендәге 2 пунктының «б» пунктчасында каралган нигез буенча уздырылган очрактан тыш;

5) тикшерү объектлары булып тормаган яки тикшерү предметына карамый торган документларны, мәгълүмат тапшыруны таләп итәргә, шулай ук мондый документларның чын нөсхәләрен алырга;

6) тикшерү үткәрү нәтиҗәсендә алынган һәм дәүләт, коммерция, хезмәт серен, закон белән саклана торган башка төрле серне тәшкил итүче мәгълүматны таратырга, Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш;

7) тикшерү уздыру өчен билгеләнгән чорларны арттырырга;

8) юридик затларга, шәхси эшкуарларга алар хисабына контрольлек чараларын үткәрү турында күрсәтмәләр яки тәкъдимнамәләр бирергә;

9) юридик заттан, шәхси эшкуардан, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалар карамагында булган рөхсәт документларын да кертеп, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән исемлеккә кертелүче документларны һәм (яки) мәгълүматларны тапшыруларын таләп итәргә;

10) юридик заттан, шәхси эшкуардан тикшерүне үткәрә башлау датасына кадәр документлар, мәгълүматлар тапшыруны таләп итәргә. Министрлык, тикшерү үткәрү турында күрсәтмә яки боерык кабул ителгәннән соң, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматларны соратырга хокуклы.

## ҮЗЛӘРЕНӘ КАРАТА КҮЗӘТЧЕЛЕК ҺӘМ КОНТРОЛЬЛЕК ЧАРАЛАРЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРЫЛА ТОРГАН ЗАТЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ ВАЗЫЙФАЛАРЫ

1.9. Юридик зат җитәкчесенең, башка вазыйфаи затының яки вәкаләтле вәкиленең, шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең тикшерүне үткәргәндә хокуклары:

1) тикшерүне үткәргәндә турыдан-туры катнашырга, тикшерү предметына кагыла торган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

2) Министрлыктан, аның тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи затларыннан тикшерү предметына кагыла торган һәм бирелеше 294-ФЗ номерлы федераль законда каралган мәгълүматларны алырга;

3) документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарының яисә җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмаларыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында Министрлыкка алынган документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән танышырга;

4) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында сорала торган документларны һәм (яисә) мәгълүматларны Министрлыкка үз ихтыяры белән тапшырырга;

5) тикшерү нәтиҗәләре белән танышырга һәм тикшерү актында тикшерү нәтиҗәләре белән үзенең танышуы, алар белән, шулай ук Министрлыкның тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи затларының аерым гамәлләре белән, ризалашуы яки ризалашмавы турында күрсәтергә;

6) тикшерүне үткәргәндә Министрлыкның тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи затларының юридик затның, шәхси эшкуарның хокуклары бозылуга китергән гамәлләренә (гамәл кылмауларына) Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм (яки) суд тәртибендә шикаять белдерергә;

7) Россия Федерациясе Президенты каршындагы Шәхси эшкуарларның хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилне яисә Татарстан Республикасы

Президенты каршындагы Шәхси эшкуарларның хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилне тикшерүдә катнашуга җәлеп итәргә.

1.10. Юридик затлар, шәхси эшкуарлар гражданлык законнары нигезендә тиешле бюджетларның акчалары хисабына, кулдан ычкындырылган файданы да (алынмый калган керемне дә) кертеп, күзәтчелекне һәм контрольне гамәлгә ашырганда тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи затларның Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә хокуксыз дип танылган гамәлләре (гамәл кылмавы) нәтиҗәсендә китерелгән зыянны каплатуга хокуклы.

Юридик затларга, шәхси эшкуарларга тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи затларның хокуклы гамәлләре аркасында китерелгән зыян, федераль законнарда каралган очраклардан тыш, капланырга тиеш түгел.

1.11. Юридик зат җитәкчесенең, аның башка вазыйфаи затының яки вәкаләтле вәкиленең, шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең тикшерү уздырганда бурычлары:

1) урынга чыгып тикшерү уздыручы вазыфаи затларга һәм урынга чыгып уздырылучы тикшерүдә катнашучы экспертларга, эксперт оешмаларына юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан эшчәнлекне гамәлгә ашырганда кулланыла торган территориягә, бинага, төзелмәгә, корылмага, бүлмәгә үтеп керүне тәэмин итәргә;

2) катнашырга яисә зарури таләпләрне үтәү буенча чараларны оештыру һәм үткәрү өчен җаваплы булган вәкаләтле вәкилләрнең катнашуын тәэмин итәргә;

3) тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи затларга тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләр буенча һәм тапшырылуы Россия Федерациясе законнарында каралган белешмәләрне һәм документларны, шулай ук телдән һәм язмача аңлатмаларны бирергә;

4) тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи затлардан бүтән документларны тапшыру таләбе белән нигезле гарызнамә алынганда яки документар тикшерү барышында ачыкланган хаталар, каршылыклар һәм (яки) документларда булган белешмәләрнең туры килмәве турында мәгълүмат килгәндә, гарызнамә яки мондый мәгълүмат алынган көннән башлап ун эш көне эчендә социаль яклау идарәләренә (бүлекләренә) гарызнамәдә күрсәтелгән документларны яки аңлатмаларны тиешенчә җибәрергә.

## КҮЗӘТЧЕЛЕКНЕ ҺӘМ КОНТРОЛЬНЕ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ НӘТИҖӘЛӘРЕ

1.12. Дәүләт функциясен үтәү нәтиҗәсе булып халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендә юридик затның, шәхси эшкуарның законнарны бозу очраклары булуын яки булмавын ачыклау тора.

Дәүләт функциясен үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора:

тикшерү акты (Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган бертиплы тикшерү акты формасы нигезендә);

юридик затта, шәхси эшкуарда булган очракта, урынга чыгып үткәрелгән тикшерүләр турында тикшерүләрне исәпкә алу журналында теркәү (тикшерүләрне

исәпкә алу журналының үрнәк рәвеше Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган);

294-ФЗ номерлы федераль законның 13.3 статьясы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 415 номерлы карары нигезендә бердәм тикшерүләр реестрына кертелгән тиешле мәгълүмат;

ТР Министрлар Кабинетының 593 номерлы карары нигезендә «Татарстан Республикасының йогынты ясау актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына кертелгән тиешле мәгълүмат;

зарури таләпләрне бозу очраклары ачыкланган очракта:

зарури таләпләр бозылуның ачыкланган очрагын бетерү турында күрсәтмә (әлеге Административ регламентка 6 нчы кушымтада китерелгән бертиплы форма).

беркетмә:

Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 5.42 статьясының 1 өлешендә каралган административ хокук бозу турында;

Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 19.7 статьясында каралган административ хокук бозу турында.

Әгәр күзәтчелекне һәм контрольне гамәлгә ашыру өчен Министрлыкка гражданнардан, шул исәптән оешмалардан мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан (алга таба – мөрәҗәгать итүче) килгән мәгълүматлар нигез булып хезмәт итсә, дәүләт функциясен үтәү нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчегә 59-ФЗ номерлы федераль законда билгеләнгән тәртиптә җавап җибәрелә.

## 2. КҮЗӘТЧЕЛЕКНЕ ҺӘМ КОНТРОЛЬНЕ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ТӘРТИБЕНӘ КАРАТА ТАЛӘПЛӘР

### КҮЗӘТЧЕЛЕКНЕ ҺӘМ КОНТРОЛЬНЕ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ТУРЫНДА ХӘБӘР ИТҮ ТӘРТИБЕ

2.1. Министрлык урнашкан урын: Казан ш., Волгоград ур., 47, тел. (843) 557-20-01, факс 520-92-87.

2.2. Министрлыкның эш графигы: көн саен, шимбә, якшәмбе һәм эшләми торган бәйрәм көннәреннән тыш, 9.00 сәгатьтән башлап 18.00 сәгатькә кадәр (җомга көннәрендә 16.45 сәгатькә кадәр), 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр төшке ашка тәнәфес ясап.

2.3. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайт адресы: http://mtsz.tatarstan.ru (алга таба – «Интернет» челтәре);

Электрон почта адресы: mtsz@tatar.ru.

Дәүләт функциясен үтәү мәсьәләләре буенча документларны һәм мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен Министрлыкның почта адресы: 420044, Казан ш., Волгоград ур., 47 й.

2.4. Министрлыкның урнашу урыны һәм эш графигы турында мәгълүмат түбәндәгечә бирелә:

Министрлык телефоннары буенча: (843) 557-20-93; 557-20-30;

Министрлыкның рәсми сайтында;

Министрлык бинасындагы мәгълүмат стендларында;

Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә.

2.5. Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләренең (алга таба – халыкның мәшгульлек үзәкләре) урнашкан урыннары турында белешмәләр, аларның адреслары һәм телефоннары әлеге Административ регламентка 1 нче кушымтада китерелде.

2.6. Халыкның мәшгульлек үзәкләре урнашкан урыннар, аларның телефоннары, эш графиклары турында мәгълүмат түбәндәгечә бирелә:

Министрлык телефоннары буенча: 557-20-01, 557-21-13, әлеге Административ регламентка 1 нче кушымтада күрсәтелгән халыкның мәшгульлек үзәкләре телефоннары буенча;

«Интернет» челтәрендә Министрлыкның http://mtsz.tatarstan.ru рәсми сайтында;

Министрлык, халыкның мәшгульлек үзәкләре биналарындагы мәгълүмат стендларында.

2.7. Министрлыкның, социаль яклау идарәләренең (бүлекләренең) урнашкан урыннары, телефоннары, эш графиклары турында мәгълүмат түбәндәгечә бирелә:

Министрлык телефоннары буенча: 557-20-01, 557-21-13, әлеге Административ регламентка 2 нче кушымтада күрсәтелгән социаль яклау идарәләре (бүлекләре) телефоннары буенча;

«Интернет» челтәрендә Министрлыкның http://mtsz.tatarstan.ru рәсми сайтында;

Министрлык, социаль яклау идарәләре (бүлекләре) биналарындагы мәгълүмат стендларында.

2.8. Әлеге Административ регламент турында мәгълүматлар Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының http://mert.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырылган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт функцияләрен үтәү буенча административ регламентларның бердәм реестрына кертелә.

2.9. Дәүләт функциясе һәм аны үтәү тәртибе турында хәбәр итү турыдан-туры Министрлык, социаль яклау идарәләре (бүлекләре) биналарында массакүләм мәгълүмат чаралары, автомәгълүмат җиткерүне, «Интернет» челтәрен дә кертеп, электрон яки телефон элемтәсе ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

2.10. Министрлыкның рәсми сайтында, Министрлыкның, халыкның мәшгульлек үзәкләренең, социаль яклау идарәләренең (бүлекләренең) мәгълүмат стендларында түбәндәге мәгълүматлар урнаштырыла:

1) кушымталары белән берлектә әлеге Административ регламентның тексты (стендларда – Административ регламентның аерым нигезләмәләре);

2) бозуларны профилактикалауның ел саен раслана торган программасы;

3) үтәлешен бәяләү контрольлек предметы булган зарури таләпләрне үз эченә алаган норматив хокукый актларның яисә аларның аерым өлешләренең исемлеге, шулай ук тиешле норматив хокукый актларның текстлары;

4) зарури таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча, шулай ук зарури таләпләрне үтәү буенча бастырып чыгарылган кулланмалар турында мәгълүмат, семинарлар һәм конференцияләр үткәрелүе, массакүләм мәгълүмат чараларында аңлату эшләре турында белешмәләр, бүтән ысуллар белән урнаштырылган бүтән мәгълүматлар турында белешмәләр. Зарури таләпләр үзгәртелгән очракта, гамәлдәге актларга кертелгән үзгәрешләрдәге зарури таләпләрне билгели торган яңа норматив хокукый актларның эчтәлеге, аларның гамәлгә керү вакытлары һәм тәртибе турында аңлатмалар, шулай ук зарури таләпләрне кертүгә һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән, зарури оештыру, техник чараларны үткәрү турында киңәшләр урнаштырыла;

5) күзәтчелекне һәм контрольне гамәлгә ашыру буенча даими, елына бер мәртәбәдән сирәк булмаган рәвештә башкарыла торган тәҗрибә гомумиләштерү буенча белешмәләр, шул исәптән зарури таләпләрне бозуның иң еш очрый торган очракларын күрсәтеп, юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан мондый бозуларга юл куймау максатларында күрелергә тиешле чараларга кагылышлы киңәшләр белән;

6) Министрлык боерыгы белән расланган ел саен уздырыла торган планлы тикшерүләр планы (алга таба – План).

## КҮЗӘТЧЕЛЕК ҺӘМ КОНТРОЛЬЛЕК ЧАРАЛАРЫН ҮТКӘРГӘН ӨЧЕН ЮРИДИК ЗАТЛАРДАН, ШӘХСИ ЭШКУАРЛАРДАН ТҮЛӘҮ АЛУНЫҢ ЯРАМАГАНЛЫГЫ

2.11. Күзәтчелек һәм контрольлек чараларын үткәргән өчен юридик затлардан, шәхси эшкуарлардан түләү алынмый, шул исәптән тикшерүләрне үткәрү өчен җәлеп ителгән очракта, экспертларның һәм экспертлык оешмаларының хезмәтләре өчен дә.

## ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН ҮТӘҮ ВАКЫТЫ

2.12. Тикшерүне (документар, урынга чыгып) үткәрү вакыты 20 эш көненнән артык була алмый.

Кече предприятиегә карата планлы урынга чыгып тикшерүләр уздыруның гомуми срогы 50 сәгатьтән артык була алмый.

Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре резидентларына тикшерүләр уздыру сроклары 473-ФЗ номерлы федераль законның 24 статьясының 4 һәм 8 өлешләрендә билгеләнгән.

2.13. Кече эшкуарлык субъекты булып торучы эш бирүчеләргә карата урынга чыгып планлы тикшерүне үткәргәндә, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында документлар һәм (яки) мәгълүматлар алу зарурлыгы килеп туган очракта, министр (министр урынбасары) тарафыннан тикшерү ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле вакытка, ләкин иң күбе ун эш көненнән артмаган чорга туктатып торылырга мөмкин. Тикшерү үткәрүне яңадан туктатып тору рөхсәт ителми.

Тикшерү үткәрүне туктатып тору чоры гамәлдә булганда кече эшкуарлык субъекты территориясендә, биналарында, төзелмәләрендә, корылмаларында, бүлмәләрендә, бүтән объектларында Министрлык вазыйфаи затларының күрсәтелгән тикшерүгә бәйле гамәлләре дә туктатып торыла.

2.14. Искәрмәле, катлаулы тикшеренүләр уздыру зарурлыгына бәйле очракларда, тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи затларның нигезле тәкъдимнәре нигезендә урынга чыгып планлы тикшерү уздыру срогы министр тарафыннан озынайтылырга мөмкин, ләкин 20 эш көненнән дә артыгракка түгел, кече предприятиеләргә карата – илле сәгатьтән дә артыгракка түгел.

2.15. Юридик затка, шәхси эшкуарга планлы тикшерүләр өч елга бер мәртәбәдән артмаган ешлыкта уздырыла.

## ПЛАНЛЫ ТИКШЕРҮЛӘР УЗДЫРУ ӨЧЕН НИГЕЗЛӘР

2.16. Планлы тикшерүләр Планнар нигезендә үткәрелә. 294-ФЗ номерлы федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда планнар тапшырылырга һәм прокуратура органнары белән килештерелергә тиеш. Министр раслаган Планнар «Интернет» челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.

Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре резидентларына карата Планнарның проектларын эшләү, планнан тыш тикшерүләр уздыруны прокуратура органнары белән килештерү РФ Хөкүмәтенең 1132 номерлы карарында, Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 817 номерлы боерыгында билгеләнгән тәртипкә ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла.

2.17. Планлы тикшерүне Планга кертү нигезе булып түбәндәге көннән башлап өч елның узып китүе тора:

юридик затны, шәхси эшкуарны дәүләт теркәвенә алу көненнән;

юридик затка, шәхси эшкуарга карата үткәрелгән соңгы планлы тикшерүне уздыру тәмамланган көннән;

юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан тиешле өлкәдә вәкаләтле дәүләт контроле (күзәтчелеге) органына эшкуарлык эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турында тапшырылган хәбәрләмгә ярашлы рәвештә, күрсәтелгән хәбәрләмне тапшыруны таләп итә торган эшләр башкарылган яисә хезмәтләр күрсәтелгән очракта, эшкуарлык эшчәнлеге гамәлгә ашырыла башлаган көннән.

## ПЛАННАН ТЫШ ТИКШЕРҮЛӘР УЗДЫРУ ӨЧЕН НИГЕЗЛӘР

2.18. Планнан тыш тикшерү үткәрү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) зарури таләпләр бозылуның ачыкланган очрагын юкка чыгару турында элегрәк бирелгән күрсәтмәнең юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан үтәлү вакыты узу;

2) тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи затның дәлилле йогынты акты, – юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән бәйләнешкә кермичә үткәрелгән контрольлек чаралары, гражданнардан, шул исәптән шәхси эшкуарлардан, юридик затлардан Министрлыкка килгән мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны, дәүләт

хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан алынган мәгълүматларны карап тикшерү яки беренчел тикшерү нәтиҗәләрен анализлау нәтиҗәсендә, – түбәндәге фактлар турында:

а) гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирәлеккә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренә), дәүләт иминлегенә зыян салыну куркынычы, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр куркынычы барлыкка килү;

б) гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирәлеккә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренә), дәүләт иминлегенә зыян салыну, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү;

3) Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәләренә туры китереп һәм прокурорның прокуратура органнарына килгән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнар үтәлешенә күзәтчелек итү кысаларында планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы таләбе нигезендә чыгарылган министр боерыгы (күрсәтмәсе).

2.19. Мөрәҗәгатьтә яки гаризада бәян ителгән мәгълүмат әлеге Административ регламентның 2.18 пунктының 2 пунктчасы нигезендә планнан тыш тикшерү уздыру өчен нигез булып торса, планнан тыш тикшерү фәкать Министрлыкка мөрәҗәгать итүче затны билгеләү мөмкинлеге булган очракта гына уздырылырга мөмкин, яки 59-ФЗ номерлы федераль законның 11 статьясының 1 өлеше нигезендә мөрәҗәгать компетенциясенә туры китереп, дәүләт органына җибәрелергә тиеш.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон документлар рәвешендә җибәрелгән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар аларның, мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон имза белән имзаланган булса, яки мөрәҗәгать итүченең бердәм идентификация һәм аутентификация системасында зарури авторлаштырылган булуын күздә тотучы мәгълүмати-коммуникация технологияләре чараларыннан файдаланып җибәрелгән булу шарты белән генә планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып хезмәт итә алалар.

2.20. Әлеге Административ регламентның 2.18 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән фактлар турындагы мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны, мәгълүматларны карап тикшергәндә элегрәк килгән, охшаш мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны, мәгълүматларны карап тикшерү нәтиҗәләре, шулай ук тиешле юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата элегрәк үткәрелгән контрольлек чараларының нәтиҗәләре исәпкә алынырга тиеш.

2.21. Зарури таләпләр бозылуга юл куйган зат турында дөрес мәгълүмат, әлеге Административ регламентның 2.18 пунктында күрсәтелгән фактлар турында җитәрлек мәгълүматлар булмаганда, Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан килгән мәгълүматка беренчел тикшерү үткәрелергә мөмкин. Килгән мәгълүматка үткәрелгән беренчел тикшерү барышында гаризаны һәм мөрәҗәгатьне җибәргән, мәгълүматлар җиткергән затлардан өстәмә белешмәләр һәм материаллар (шул исәптән телдән) соратып алу буенча чаралар күрелә, юридик затның, шәхси

эшкуарның Министрлык карамагында булган документлары карап тикшерелә, зарурлык булганда, юридик зат, шәхси эшкуар белән бәйләнешкә кермичә генә һәм күрсәтелгән затларга мәгълүматлар тапшыру һәм Министрлык таләпләрен үтәү буенча бурычлар йөкләмичә генә контрольлек чаралары үткәрелә. Беренчел тикшерү кысаларында юридик заттан, шәхси эшкуардан алынган мәгълүматка карата аңлатмалар соратылырга мөмкин, ләкин мондый аңлатмаларны һәм башка төрле документларны тапшыру мәҗбүри булып саналмый.

2.22. Беренчел тикшерү нәтиҗәләре буенча зарури таләпләр бозылуга юл куйган затлар ачыкланганда, әлеге Административ регламентның 2.18 пунктында күрсәтелгән фактлар турында җитәрлек күләмдә мәгълүматлар алынганда, Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты, әлеге Административ регламентның 2.18 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча, планнан тыш тикшерү үткәрү турында дәлилле йогынты актын әзерли. Беренчел тикшерү нәтиҗәләре буенча юридик затны, шәхси эшкуарне җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрелми.

2.23. Министрның (министр урынбасарының) карары буенча, әгәр тиешле тикшерүне башлаганнан соң, аны оештыру өчен нигез булган мөрәҗәгатьнең яки гаризаның аноним булуы ачыкланса, яисә мөрәҗәгатьтә яки гаризада белә торып ялган белешмәләр булуы ачыкланса, беренчел тикшерү, планнан тыш тикшерү туктатыла.

2.24. Министрлык, әгәр гаризаларда, мөрәҗәгатьләрдә белә торып ялган белешмәләр күрсәтелсә, гражданиннан, шул исәптән юридик заттан, шәхси эшкуардан, аталган затлардан килгән гаризаларны, мөрәҗәгатьләрне карап тикшерүгә бәйле рәвештә Министрлык тарафыннан тотылган чыгымнарны түләттерү турында судка шикаять белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

2.25. Юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш урынга чыгып тикшерү Министрлык тарафыннан әлеге Административ регламентның 2.18 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча, мондый юридик затның, шәхси эшкуарның эшчәнлеге гамәлгә ашырылган урын буенча, прокуратура органы белән килештергәннән соң үткәрелергә мөмкин.

## КҮЗӘТЧЕЛЕКНЕ ҺӘМ КОНТРОЛЬНЕ ТУРЫДАН-ТУРЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУЧЫ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАР

2.26. Әлеге Административ регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән вазыйфаи затлар турыдан-туры дәүләт функциясен үтәүче булып тора.

Министрлыкның административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеге Министрлыкның 2007 елның 12 ноябрендәге 346 номерлы боерыгы белән расланды.

## 294-ФЗ НОМЕРЛЫ ФЕДЕРАЛЬ ЗАКОННЫ БОЗГАН ӨЧЕН ЮРИДИК ЗАТЛАРНЫҢ, ШӘХСИ ЭШКУАРЛАРНЫҢ ҖАВАПЛЫ БУЛУЫ

2.27. 294-ФЗ номерлы федераль закон бозылуга юл куйган, тикшерүләрне үткәрүгә нигезсез рәвештә каршы төшүче, тикшерүләрне үткәрүдән читләшүче һәм

(яки) билгеләнгән чорларда Министрлыкның зарури таләпләрнең ачыкланган бозуларын бетерү турында күрсәтмәсен үтәмәүче юридик затлар, аларның җитәкчеләре, бүтән вазыйфаи затлары яки вәкаләтле вәкилләре, шәхси эшкуарлар, аларның вәкаләтле вәкилләре Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.

## ТИКШЕРҮ УЗДЫРГАНДА МИНИСТРЛЫКНЫҢ, АНЫҢ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРЫНЫҢ ҖАВАПЛЫЛЫГЫ

2.28. Министрлык, аның тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи затлары тикшерү үткәргәндә, тиешенчә, функцияләрне, хезмәт вазыйфаларын тиешле дәрәҗәдә үтәмәгән очракта, хокукка каршы килә торган гамәлләрне кылганда (гамәл кылмаганда), Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.

## 3. ЮРИДИК ЗАТЛАРГА, ШӘХСИ ЭШКУАРЛАРГА КАРАТА БЕЛДЕРЕЛӘ ТОРГАН ЗАРУРИ ТАЛӘПЛӘР

3.1. Үтәлеше Министрлык тарафыннан тикшерүдә тотыла торган, юридик затларга, шәхси эшкуарларга белдерелә торган зарури таләпләр исемлеге, аларны билгеләүче норматив хокукый актларның исемлеге, тикшерү барышында юридик затларга, шәхси эшкуарларга күрсәтелә торган документлар исемлеге әлеге Административ регламентның 3 нче кушымтасында күрсәтелде.

3.2. Зарури таләпләр бозылуны профилактикалау максатларында Министрлык шушы Административ регламентның 3.3-3.15 пунктлары нигезендә зарури таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтүләр бирә.

3.3. Министрлыкта килгән мөрәҗәгатьләрдә һәм гаризаларда (авторлыгы расланмаган мөрәҗәгатьләрдән һәм гаризалардан тыш), дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан алынган мәгълүматларда бәян ителгән зарури таләпләрне бозуларның әзерләнеп ятуы яисә бозылу билгеләре хакында мәгълүматлар булганда, әгәр зарури таләпләрне бозу гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерүе турында яки күрсәтелгән нәтиҗәләр барлыкка килү куркынычын тудыру турында расланган белешмәләр булмаса, Министрлык юридик затка, шәхси эшкуарга зарури таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтү белдерә һәм юридик затка, шәхси эшкуарга зарури таләпләрнең үтәлүен тәэмин итү буенча чаралар күрергә һәм бу хакта шул кисәтүдә билгеләнгән чорда Министрлыкка хәбәр итәргә тәкъдим итә.

3.4. Кисәтү җибәрү турындагы карар министр, министр урынбасары тарафыннан яисә Министрлык боерыгы нигезендә вәкаләт бирелгән бүтән вазыйфаи зат тарафыннан Министрлыкның тикшерү уздыру вәкаләте бирелгән вазыйфаи заты тәкъдимнәре нигезендә шушы Административ регламентның 3.3 пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар булганда кабул ителә.

3.5. Кисәтүне төзү һәм җибәрү Министрлыкның тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи заты шушы Административ регламентның 3.3 пунктында күрсәтелгән

мәгълүматларны алган көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

3.6. Күрсәтмәдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) Министрлыкның исеме;

б) кисәтүнең датасы һәм номеры;

в) юридик затның аталышы, шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

г) зарури таләпләргә, норматив хокукый актларга күрсәтү, аларның күрсәтелгән таләпләрне күздә тотучы структур берәмлекләрен дә кертеп;

д) юридик затның, шәхси эшкуарның кайсы гамәлләре (гамәл кылмавы) зарури таләпләр бозылуга китерүе яисә китерергә мөмкин булуы турында мәгълүмат;

е) юридик затка, шәхси эшкуарга зарури таләпләр үтәлүне тәэмин итү буенча чаралар күрүне тәкъдим итү;

ж) юридик затка, шәхси эшкуарга кисәтүнең үтәлеше турында Министрлыкка хәбәрләмә җибәрү турында тәкъдим итү;

з) юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан кисәтүнең үтәлеше турында хәбәр җибәрү вакыты (кисәтү җибәрелгән көннән башлап кимендә 60 календарь көне);

и) почта адресын һәм электрон почта адресын кертеп, Министрлыкның элемтә белешмәләре, шулай ук ризасызлыклар, кисәтүнең үтәлеше турындагы хәбәр бирүнең мөмкин булган бүтән ысуллары.

3.7. Кисәтүдә юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан белешмәләр һәм документлар тапшырылу турында таләп була алмый.

3.8. Кисәтү кәгазьдә кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы итеп, яисә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, әлеге Административ регламентның 3.4 пунктында күрсәтелгән кисәтүне җибәрү турында карар кабул иткән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы куелган электрон документ рәвешендә җибәрүне дә кертеп, шул исәптән юридик затның, шәхси эшкуарның, тиешенчә, Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында күрсәтелгән яисә юридик затның, шәхси эшкуарның рәсми сайтында Россия Федерациясе законнары нигезендә зарури рәвештә урнаштырылырга тиешле мәгълүматлар составында урнаштырылган электрон почта адресы буенча, яисә «Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә, юридик зат, шәхси эшкуар өчен мөмкин булган бүтән ысул белән җибәрелә.

3.9. Кисәтүне карау нәтиҗәләре буенча юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан Министрлыкка ризасызлыклар тапшырылырга мөмкин.

3.10. Ризасызлыкларда түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) юридик затның аталышы, шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

б) салым түләүче – юридик затның, шәхси эшкуарның индентификацияләү номеры;

в) юридик затның, шәхси эшкуарның адресына җибәрелгән кисәтүнең датасы һәм номеры;

г) юридик затның, шәхси эшкуарның зарури таләпләр бозылуга китерә торган яки китерергә мөмкин булган кисәтүдә күрсәтелгән гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата позицияне нигезләү.

3.11. Ризасызлыклар Министрлыкка юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан кәгазьдә почта аша хат итеп, яисә шәхси эшкуарның, юридик зат исеменнән гамәл кылу вәкаләте бирелгән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә кисәтүдә күрсәтелгән Министрлыкның электрон почта адресына, яисә кисәтүдә күрсәтелгән бүтән ысуллар белән җибәрелә.

3.12. Министрлык ризасызлыкларны карап тикшерә, карап тикшерү йомгаклары буенча юридик затка, шәхси эшкуарга ризасызлыкларны алган көннән башлап 20 эш көне эчендә әлеге Административ регаментның 3.8 пунктында билгеләнгән тәртиптә җавап җибәрә. Ризасызлыкларны карап тикшерү нәтиҗәләре Министрлык тарафыннан зарури таләпләр бозылуны профилактикалау буенча чараларны оештыру һәм үткәрү максатларында һәм юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын һәм ирекләрен чикләүгә бәйле булмаган бүтән максатларда файдаланыла.

3.13. Ризасызлыклар булмаганда, юридик зат, шәхси эшкуар кисәтүдә күрсәтелгән чорда Министрлыкка кисәтүне үтәү турында хәбәр җибәрә.

3.14. Кисәтүне үтәү турындагы хәбәрдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) юридик затның аталышы, шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

б) салым түләүче – юридик затның, шәхси эшкуарның индентификацияләү номеры;

в) юридик затның, шәхси эшкуарның адресына җибәрелгән кисәтүнең датасы һәм номеры;

г) кисәтүне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча зарури таләпләр үтәлешен тәэмин итү буенча күрелгән чаралар турында мәгълүматлар.

3.15. Хәбәр Министрлыкка юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан кәгазьдә почта аша хат итеп, яисә шәхси эшкуарның, юридик зат исеменнән гамәл кылу вәкаләте бирелгән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә кисәтүдә күрсәтелгән Министрлыкның электрон почта адресына, яисә кисәтүдә күрсәтелгән бүтән ысуллар белән җибәрелә.

## 4. ТИКШЕРҮ ҮТКӘРГӘНДӘ ЮРИДИК ЗАТ, ШӘХСИ ЭШКУАР ТАРАФЫННАН ТАПШЫРЫЛА ТОРГАН ДОКУМЕНТЛАР

Тикшерү уздыруның максатларына һәм бурычларына ирешү өчен юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан тапшырыла торган документларның исемлеге, шулай ук мондый документларның формаларын раслаган норматив хокукый актларның исемлеге әлеге Административ регламентның 4 нче кушымтасында китерелде.

## 5. АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАРНЫҢ (ГАМӘЛЛӘРНЕҢ) СОСТАВЫ,

## ЭЗЛЕКЛЕЛЕГЕ ҺӘМ АЛАРНЫ ҮТӘҮ ВАКЫТЛАРЫ, АЛАРНЫ ҮТӘҮ ТӘРТИБЕНӘ КАРАТА ТАЛӘПЛӘР, ШУЛ ИСӘПТӘН АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАРНЫ (ГАМӘЛЛӘРНЕ) ЭЛЕКТРОН РӘВЕШТӘ ҮТӘҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

5.1. Дәүләт функциясе планлы һәм планнан тыш тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла, алар документар тикшерү һәм (яки) урынга чыгып тикшерү формасында уздырыла.

Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре резидентларына карата күзәтчелек һәм контроль әлеге Административ регламент нигезендә һәм 473-ФЗ номерлы федераль законның 24 статьясында, РФ Хөкүмәтенең 1132 номерлы карарында, Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 817 номерлы боерыгында билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

5.2. Дәүләт функциясе түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

планлы урынга чыгып һәм планлы документар тикшерүләр уздыруны планлаштыру һәм әзерләү;

урынга чыгып планлы тикшерү уздыру;

планлы документар тикшерү уздыру;

планнан тыш урынга чыгып һәм планнан тыш документар тикшерүләр уздыруны әзерләү;

урынга чыгып планнан тыш тикшерү уздыру;

планнан тыш документар тикшерү уздыру;

ачыкланган бозуларның нәтиҗәсен чикләү һәм (яки) бетерү буенча Россия Федерациясе законнарында каралган чараларны күрү.

5.3. Дәүләт функциясен үтәүнең блок-схемасы әлеге Административ регламентка 5 нче кушымтада күрсәтелде.

5.4. Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда дәүләт функциясен үтәүне туктатып тору рөхсәт ителә.

## «ПЛАНЛЫ УРЫНГА ЧЫГЫП ҺӘМ ПЛАНЛЫ ДОКУМЕНТАР ТИКШЕРҮЛӘР УЗДЫРУНЫ ПЛАНЛАШТЫРУ ҺӘМ ӘЗЕРЛӘҮ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.5. «Планлы урынга чыгып һәм планлы документар тикшерүләр уздыруны планлаштыру һәм әзерләү» административ процедурасын башлап җибәрү өчен еллык Планны әзерләү һәм аның проектын килештерү өчен прокуратура органнарына җибәрү срогының килеп җитүе нигез булып тора.

5.6. Министр ел саен төзелә торган Планны әзерләү өчен җаваплы башкаручыны (җаваплы башкаручыларны) билгели (алга таба – ел саен төзелә торган Планны әзерләү буенча вазыйфаи зат).

үтәү вакыты: планлы тикшерүләрне үткәргән елдан соң килүче елның 1 августыннан да соңга калмыйча.

5.7. Планны әзерләү буенча вазыйфаи зат түбәндәге административ гамәлләрне гамәлгә ашыра:

1) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 489 номерлы карары белән расланган Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затларга, шәхси эшкуарларга ел саен уздырыла торган планлы тикшерүләрнең планнарын әзерләү кагыйдәләрендә каралган форма буенча еллык План проектын төзи, аны министр урынбасары һәм министр белән килештерә;

үтәү вакыты: планлы тикшерүләрне үткәргән елдан соң килүче елның 23 августыннан соңга калмыйча;

2) планлы тикшерүләрне уздыру елыннан алдагы елның 1 сентябренә кадәр кәгазьдә (электрон формада күчермәсен теркәп) еллык План проектын килештерү өчен кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы итеп яки «Электрон имза турында» федераль закон нигезендә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза (алга таба – көчәйтелгән квалификацияле электрон имза) белән имзаланган электрон документ формасында прокуратура органына җибәрә.

5.8. Еллык план проекты прокуратура органы тарафыннан каралгач һәм тәкъдимнәр кертелгәч, Планны әзерләү буенча җаваплы башкаручы:

1) прокуратура органыннан килгән тәкъдимнәрне исәпкә алып, еллык план проектына төзәтмәләр кертә;

2) еллык план проектын кертелгән үзгәрешләре белән бергә министр урынбасары белән килештерә;

3) еллык план проектын раслау өчен министрга җибәрә;

4) еллык план министр тарафыннан раслангач, аны кәгазьдә (күчермәсен электрон рәвештә теркәп) тиешле прокуратура органына кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы рәвешендә яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында җибәрә;

үтәү вакыты: ел саен төзелә торган, расланган Планны прокуратурага җибәрү – планлы тикшерүләрне уздыру елыннан алда килүче елның 1 ноябренә кадәр.

5.9. Планны әзерләү буенча вазыйфаи зат расланган еллык планның Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылуын оештыра;

үтәү вакыты: агымдагы календарь елының 31 декабренә кадәр.

5.10. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 489 номерлы карарында билгеләнгән очракларда дәлилләүче документлар (мисал өчен, Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан йә Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан юридик затны, шәхси эшкуарны дәүләт теркәвенә алу, ликвидацияләү (реестрдан төшерү) турында язу теркәлүе турында өземтәләр) булганда еллык планга үзгәрешләр кертү рөхсәт ителә.

Еллык планга үзгәрешләр кертү министр боерыгы нигезендә гамәлгә ашырыла. Еллык планга кертелгән үзгәрешләр турында белешмәләр билгеләнгән тәртиптә алар кертелгәннән соң 3 эш көне эчендә кәгазьдә (күчермәсен электрон рәвештә теркәп) кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы рәвешендә яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында тиешле прокуратура органына җибәрелә һәм үзгәрешләр кертелгән көннән соң 5 эш көне эчендә Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.

5.11. Министр План нигезендә эш бирүчегә тикшерү уздыру өчен боерык

нигезендә социаль яклау идарәләре (бүлекләре) белгечләре вазыйфаи затлары исәбеннән җаваплы башкаручыны (җаваплы башкаручыларны) (тикшерү уздыруга вәкаләтле зат) билгели;

үтәү вакыты: эш бирүчегә тикшерү уздыра башлаганчыга кадәр кимендә өч атна алдан яки Планны төзегәннән соң турыдан-туры.

5.12. Планны әзерләү буенча вазыйфаи зат «Планлы урынга чыгып һәм планлы документар тикшерүләр уздыруны планлаштыру һәм әзерләү» административ процедурасының түбәндәге административ гамәлләрен башкара:

1) Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган тикшерү уздыру турында күрсәтмәнең яки боерыкның бертип формасына туры китереп, аны уздыра башларга кимендә 2 атна алдан тикшерү уздырылачагы турында боерык (күрсәтмә) проектын әзерли;

тикшерү уздыру турында боерыкта (күрсәтмәдә) түбәндәгеләр күрсәтелә:

социаль яклау идарәсенең (бүлегенең) исеме, шулай ук дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) төре (төрләре);

тикшерүне үткәрүгә вәкаләт бирелгән вазыйфаи затның яисә вазыйфаи затларның, шулай ук тикшерү үткәрү өчен җәлеп ителә торган экспертларның, эксперт оешмалары вәкилләренең фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре, вазыйфалары;

үзләренә карата тикшерү үткәрелә торган юридик затның аталышы яисә шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме, юридик затларның (аларның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләренең) урнашу урыннары яисә шәхси эшкуарларның фактта эшчәнлекләрен гамәлгә ашыру урыннары;

тикшерүне максатлары, бурычлары, предметы һәм аны үткәрү вакыты;

тикшерүне үткәрүнең хокукый нигезләре;

тикшерелергә тиешле зарури таләпләр;

тикшерүне үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешү өчен зарури булган контрольлек чараларын үткәрү вакытлары һәм аларның исемлеге;

дәүләт контролен (күзәтчелеген) үтәү буенча административ регламентлар исемлеге;

тикшерү үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешү өчен юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар исемлеге;

тикшерүне үткәрә башлау һәм тәмамлау даталары;

министрның, министр урынбасары күрсәтмәсенең яки боерыгының бертип формасында каралган булса, бүтән белешмәләр;

2) тикшерү уздыру турында боерыкка (күрсәтмәгә) министрның (министр урынбасарының) кул куюын тәэмин итә.

5.13. План әзерләү буенча вазыйфаи зат тарафыннан планлы урынга чыгып һәм планлы документар тикшерүләр уздыруны планлаштыру һәм әзерләү буенча карар кабул итү критерияләре булып әлеге Административ регламентның 2.17 пунктында күрсәтелгән очраклар тора.

5.14. Тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи зат «Планлы урынга чыгып һәм

планлы документар тикшерүләр уздыруны планлаштыру һәм әзерләү» административ процедурасының түбәндәге административ гамәлләрен башкара:

министр, министр урынбасары күрсәтмәсенең яки боерыгының күчермәсен кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы җибәрү юлы белән һәм (яисә) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм юридик затның, шәхси эшкуарның электрон почта адресына җибәрелгән электрон документ рәвешендә, әгәр мондый адрес тиешенчә юридик затларның бердәм реестрында, шәхси эшкуарларларның бердәм дәүләт реестрында булса, яисә элегрәк юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан Министрлыкка тапшырылган булса, яисә бүтән үтемле ысул белән юридик затка, шәхси эшкуарга планлы тикшерүне үткәрә башлау хакында хәбәр итүне тәэмин итә;

үтәү вакыты: юридик затка, шәхси эшкуарга хәбәр итү – тикшерүне үткәрә башларга кимендә өч эш көненнән дә соңга калмыйча.

5.15. «Планлы урынга чыгып һәм планлы документар тикшерүләр уздыруны планлаштыру һәм әзерләү» административ процедурасының нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

тикшерү уздыру өчен вазыйфаи затны билгеләү;

тикшерү уздыру турында боерык (күрсәтмә);

юридик зат, шәхси эшкуар адресына тикшерү уздыру турында хәбәр җибәрү.

5.16. «Планлы урынга чыгып һәм планлы документар тикшерүләр уздыруны планлаштыру һәм әзерләү» административ процедурасын үтәү нәтиҗәләрен теркәү Министрлыкта эш башкаруны алып бару кагыйдәләре нигезендә, билгеләнгән тәртиптә әлеге Административ регламентның 5.15 пунктында күрсәтелгән хәбәр, боерык (күрсәтмә) күчермәләрен исәпкә алу һәм эш материалларында саклау, шулай ук әлеге документларның белешмәләрен аерым электрон формада саклау юлы белән гамәлгә ашырыла.

## «ПЛАНЛЫ УРЫНГА ЧЫГЫП ТИКШЕРҮ УЗДЫРУ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.17. «Планлы урынга чыгып тикшерү уздыру» административ процедурасын башлап җибәрү өчен тиешле юридик затны, шәхси эшкуарны Министрлыкның юридик затларга, шәхси эшкуарларга тикшерүләр уздыру буенча еллык Планына кертү, «Планлы урынга чыгып һәм планлы документар тикшерүләр уздыруны әзерләү» административ процедурасының төгәлләнүе, шулай ук документар тикшерү барышында түбәндәгеләрнең мөмкин булмавы нигез булып тора:

эшкуарлык эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турындагы хәбәрдә һәм юридик затның, шәхси эшкуарның Министрлык карамагында булган бүтән документларында бәян ителгән белешмәләрнең тулы һәм дөрес булуын тикшереп белү;

юридик затның, шәхси эшкуарның эшчәнлегенең зарури таләпләргә туры килүен контроль буенча тиешле чараларны үткәрмичә бәяләү.

5.18. Тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи зат түбәндәге административ гамәлләрне башкара:

1) юридик затка, шәхси эшкуарга Министрлык боерыгында (күрсәтмәсендә) билгеләнгән срокта килә, хезмәт таныклыгын күрсәтә һәм юридик зат җитәкчесенә, шәхси эшкуарга тикшерү уздыру турында боерык (күрсәтмә) күчермәсен тапшыра, юридик зат җитәкчесенә, шәхси эшкуарга тикшерү уздыруның максатлары, бурычлары, нигезләре, контрольлек чараларының төрләре һәм күләме, аны уздыру сроклары һәм шартлары турында мәгълүмат бирә;

үтәү вакыты: юридик затка, шәхси эшкуарга килгәч;

2) документта булган, тикшерүнең максатларына, бурычларына һәм предметына бәйле белешмәләрне өйрәнә;

3) юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан түбәндәге нигезләмәләрнең (әлеге Административ регламентның 3 нче кушымтасына туры китереп, тикшергәндә эш бирүчеләргә белдерелә торган зарури таләпләрнең) үтәлүен тикшерә:

а) инвалидларны эшкә алу өчен билгеләнгән квота нигезендә, инвалидларны эшкә урнаштыру өчен булдырылган яки бүлеп бирелгән эш урыннары исәбенең халыкны эшкә урнаштыру һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге законнарның таләпләренә туры килүен;

б) фактты эшләүче инвалидлар исәбенең инвалидларны эшкә алу буенча эш урыннарының исәпләнгән исәбенә туры килүен;

в) юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан инвалидларны һөнәри тернәкләндерү һәм аларга эшкә урнашуда булышлык күрсәтү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматларның халыкның мәшгульлек үзәгенә билгеләнгән срокларда тапшырылуының тулы һәм дөрес булуын;

г) юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан инвалидларны эшкә алу өчен квотаны үтәү турындагы мәгълүматның халыкның мәшгульлек үзәгенә билгеләнгән срокларда тапшырылуының тулы һәм дөрес булуын;

4) зарурлык булганда планлы урынга чыгып уздырылган тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләр буенча документларны һәм материалларны сората, шулай ук юридик зат җитәкчесеннән, шәхси эшкуардан язмача аңлатмалар ала, юридик затның җитәкчесе һәм/яки хезмәткәре, шәхси эшкуар белән тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләр буенча әңгәмә уздыра (әгәр урынга чыгып тикшерү документар тикшерүдән соң уздырылса, урынга чыгып тикшерү уздырганда юридик заттан, шәхси эшкуардан алар тарафыннан документар тикшерү барышында тапшырылган документларны һәм (яки) мәгълүматны тапшыруны таләп итү тыела);

5) тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләр буенча тапшырылган документларга, материалларга һәм аңлатмаларга анализ ясый һәм халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннары булдыру (бүлеп бирү) өлкәсендәге закон бозуларның булуы (булмавы) турында карар кабул итә;

6) бозу фактлары ачыкланганда:

а) бозу фактларын раслаучы документларның күчермәләрен ясый һәм билгеләнгән тәртиптә таныклый (алга таба – раслаучы документлар);

б) халыкны эш белән тәэмин итү турындагы законнарны бозу фактлары турында белешмәләрне раслаучы документларның күчермәләрен теркәп, тикшерү акты проектына кертә;

7) юридик затта, шәхси эшкуарда булган очракта, тикшерү турында тикшерүләрне исәпкә алу журналында язу терки, анда социаль яклау идарәсенең (бүлегенең) исеме, тикшерүне уздыра башлау һәм тәмамлау даталары, аны уздыру вакыты, тикшерүнең хокукый нигезләре, максатлары, бурычлары һәм предметы, ачыкланган бозулар һәм бирелгән күрсәтмәләр турында белешмәләр була, тикшерүне уздыручы вазыйфаи затның яисә вазыйфаи затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре һәм вазыйфалары, аның яисә аларның имзалары күрсәтелә;

8) эш бирүчедә тикшерүләрне исәпкә алу журналы булмаганда, тикшерү акты проектына тиешле язуны терки;

9) тикшерү акты проектын әзерли (тикшерү актының бертип формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган), юридик зат җитәкчесе, шәхси эшкуар тарафыннан тикшерү уздырылганда тапшырылган документларның исемлеген һәм күчермәләрен (алга таба – кушымталар) аңа теркәп куя.

үтәү вакыты: тикшерүне тәмамлаганнан соң турыдан-туры;

10) 2 нөсхәдә тикшерү актына кул куя;

үтәү вакыты: актны төзегәннән соң шунда ук;

11) тикшерү актының бер нөсхәсен кушымталарының күчермәләре белән юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә (тикшерү акты белән танышып чыгу турында яки танышын чыгудан баш тарту турында кул куйдыртып) тапшыра йә, тикшерелә торган затның электрон формада үзара хезмәттәшлек итүгә ризалыгы булган очракта, тикшерү актының бер нөсхәсен кушымталарының күчермәләре белән бергә әлеге актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә тапшыра (актны төзегән затның көйчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган, электрон документ формасында тикшерелә торган затка күрсәтелгән документның алынуын раслауны тәэмин итәрлек ысул белән җибәрелгән акт тикшерелүче зат тарафыннан алынган булып санала);

үтәү вакыты: актка кул куйганнан соң турыдан-туры;

12) юридик затның җитәкчесе, бүтән вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар булмаган очракта, шулай ук тикшерелә торган зат тикшерү акты белән танышып чыгу турында язу бирүдән баш тартканда яисә танышып чыгудан баш тарткан очракта, тикшерү актының кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы белән җибәрелүен тәэмин итә, әлеге белдерү социаль яклау идарәсе (бүлеге) эшендә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә;

үтәү вакыты: актка кул куйганнан соң турыдан-туры;

13) тикшерү актының икенче нөсхәсенә тиешле язуны терки, аңа заказлы почта юлламасын тапшыру турында белдерүне һәм (яки) тикшерү актының алынуының башкача расламасын терки;

үтәү вакыты: тикшерү актын почта аша заказлы хат итеп җибәргәннән соң турыдан-туры;

14) тикшерү актына юридик зат җитәкчесенең, шәхси эшкуарның язмача ризасызлыкларын (булган очракта) терки, әгәр юридик зат җитәкчесе, шәхси эшкуар тикшерү актының эчтәлеге белән риза булмаса;

үтәү вакыты: юридик зат җитәкчесенең, шәхси эшкуарның ризасызлыкларын алганнан соң турыдан-туры;

15) тикшерү актында халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннары булдыру (бүлеп бирү) өлкәсендәге законнарның бозылу фактлары ачыкланганда, әлеге Административ регламентның 5.47 пунктында каралган административ гамәлләрне башкара.

5.19. Тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан планлы урынга чыгып уздырылган тикшерү нәтиҗәләре буенча карар кабул итү критериясе булып тикшерү барышында тапшырылган документларның һәм материалларның халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннары булдыру (бүлеп бирү) өлкәсендәге законнарга туры килүе (туры килмәве) тора.

5.20. «Планлы урынга чыгып тикшерү уздыру» административ процедурасының нәтиҗәсе булып халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннары булдыру (бүлеп бирү) өлкәсендәге законнары бозылуның ачыкланган очракларын яки мондый очракларның булмавын теркәлгән тикшерү акты тора.

5.21. «Планлы урынга чыгып тикшерү уздыру» административ процедурасын үтәү нәтиҗәсе тикшерү актында, тикшерүләрнең бердәм реестрында, Министрлыкның рәсми сайтында электрон формада теркәлә;

«Планлы урынга чыгып тикшерү уздыру» административ процедурасын үтәү срогы – әлеге Административ регламентның 2.12 пунктына ярашлы рәвештә.

5.22. Әгәр шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең яки башка вазыйфаи затының булмавына бәйле рәвештә, яисә юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан эшчәнлекнең фактта башкарылмавына бәйле рәвештә, шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең яки башка вазыйфаи затының бүтән төрле, тикшерүне үткәрү мөмкинлеген юкка чыгаручы гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында планлы яки планнан тыш урынга чыгып тикшерүне үткәрү мөмкин булмаса, тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи зат, аны үткәрү мөмкинлеген юкка чыгаручы сәбәпләрне күрсәтеп, тиешле тикшерүне үткәрү мөмкинлегенең булмавы хакында акт төзи. Бу очракта Министрлык, тиешле тикшерүне үткәрүнең мөмкин булмавы хакында акт төзелгән көннән башлап өч ай дәвамында, мондый юридик затка, шәхси эшкуарга карата, планлы тикшерүне еллык планлы тикшерүләр планына кертмичә һәм юридик затка, шәхси эшкуарга алдан хәбәр итмичә, планлы яки планнан тыш урынга чыгып тикшерү үткәрү турында карар кабул итәргә хокуклы.

## «ПЛАНЛЫ ДОКУМЕНТАР ТИКШЕРҮ УЗДЫРУ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.23. «Планлы документар тикшерү уздыру» административ процедурасын башлап җибәрү нигезе булып юридик затны, шәхси эшкуарны еллык Планга кертү

һәм «Планлы урынга чыгып һәм планлы документар тикшерүләр уздыруны әзерләү» административ процедурасының тәмамлануы нигез булып тора. План «Интернет» челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.

5.24. Тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи зат түбәндәге административ гамәлләрне башкара:

1) юридик затның, шәхси эшкуарларның Министрлык карамагында булган материалларын һәм документларын, алдагы тикшерүләрнең актларын, әлеге юридик затка, шәхси эшкуарга карата административ хокук бозулар турында эшләрне карау материалларын һәм билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга карата гамәлгә ашырылган күзәтчелек һәм контрольнең нәтиҗәләре турында бүтән документларны өйрәнә;

2) Министрлык карамагында булган документлардагы белешмәләрнең дөреслеге шик тудырганда яки әлеге белешмәләр юридик затның, шәхси эшкуарның халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге законнарның зарури таләпләрен үтәвен бәяләргә мөмкинлек бирмәгән очракта, документар тикшерү уздыру барышында карау өчен кирәкле башка документларны тапшыруны таләп итеп, юридик зат, шәхси эшкуар адресына нигезле гарызнамә җибәрә (кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы итеп яки факсимиль элемтә чараларыннан файдаланып яки электрон почта буенча), гарызнамәгә тикшерү уздыру турында боерыкның (күрсәтмәнең) мөһер белән таныкланган күчермәсен терки;

3) зарурлык булганда юридик заттан, шәхси эшкуардан (фәкать тикшерү уздыру турында күрсәтмә яки боерык кабул ителгәннән соң гына), шул исәптән электрон рәвештә, әлеге Административ регламентка 7 нче кушымтада күрсәтелгән документларны һәм (яисә) мәгълүматларны шушы документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 323 номерлы карарында билгеләнгән чорларда һәм тәртиптә сората һәм ала;

4) юридик зат, шәхси эшкуар тапшырган, элегрәк тапшырылган документларның дөреслегенраслый торган аңлатмаларны һәм документларны карый. Гарызнамәдә күрсәтелгән документлар мөһер (булган очракта) һәм шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең, башка вазыйфаи затының тиешенчә имзасы белән таныкланган күчермәләре рәвешендә тапшырыла. Юридик зат, шәхси эшкуар гарызнамәдә күрсәтелгән документларны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә дә тапшырырга хокуклы;

5) юридик зат җитәкчесен, бүтән вазыйфаи затын яисә вәкаләтле вәкилен, шәхси эшкуарны, аның вәкаләтле вәкилен ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән таныштыра;

6) юридик заттан, шәхси эшкуардан килгән материалларны һәм документларны өйрәнү нәтиҗәсендә халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннары булдыру (бүлеп бирү) өлкәсендәге

законнарның бозылу очраклары булуы (булмавы) турында карар кабул итә, юридик затның, шәхси эшкуарның түбәндәге нигезләмәләрне үтәвен тикшерү максатында:

а) инвалидларны эшкә алу өчен билгеләнгән квота нигезендә, инвалидларны эшкә урнаштыру өчен булдырылган яки бүлеп бирелгән эш урыннары исәбенең халыкны эшкә урнаштыру һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге законнарның таләпләренә туры килүен;

б) фактта эшләүче инвалидлар исәбенең инвалидларны эшкә алу буенча эш урыннарының исәпләнгән исәбенә туры килүен;

в) юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан инвалидларны һөнәри тернәкләндерү һәм аларга эшкә урнашуда булышлык күрсәтү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматларның халыкның мәшгульлек үзәгенә билгеләнгән срокларда тапшырылуының тулы һәм дөрес булуын;

г) халыкның мәшгульлек үзәгенә юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан тапшырылган мәгълүматның тулы һәм дөрес булуын;

7) тикшерү акты проектын әзерли.

үтәү вакыты: тикшерүне тәмамлаганнан соң турыдан-туры;

8) 2 нөсхәдә тикшерү актына кул куя.

үтәү вакыты: актны рәсмиләштергәннән соң турыдан-туры;

9) тикшерү актының бер нөсхәсен кушымталарының күчермәләре белән юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә (тикшерү акты белән танышып чыгу турында яки танышын чыгудан баш тарту турында кул куйдыртып) тапшыра йә, тикшерелә торган затның электрон формада үзара хезмәттәшлек итүгә ризалыгы булган очракта, тикшерү актының бер нөсхәсен кушымталарының күчермәләре белән бергә әлеге актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә тапшыра (актны төзегән затның көйчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган, электрон документ формасында тикшерелә торган затка күрсәтелгән документның алынуын раслауны тәэмин итәрлек ысул белән җибәрелгән акт тикшерелүче зат тарафыннан алынган булып санала).

үтәү вакыты: актка кул куйганнан соң турыдан-туры;

10) юридик затның җитәкчесе, бүтән вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар булмаган очракта, шулай ук тикшерелә торган зат тикшерү акты белән танышып чыгу турында язу бирүдән баш тартканда яисә танышып чыгудан баш тарткан очракта, тикшерү актының кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы белән җибәрә, әлеге белдерү социаль яклау идарәсе (бүлеге) эшендә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә.

үтәү вакыты: тикшерү акты рәсмиләштерелгәннән һәм имзаланганнан соң турыдан-туры;

11) заказлы почта юлламасын кулга тапшыру турында хәбәрне һәм (яки) акт алынуга башка төрле расламаны, шулай ук юридик зат җитәкчесе, шәхси эшкуар тикшерү актының эчтәлеге белән риза булмаган очракта, юридик зат җитәкчесенең, шәхси эшкуарның язмача ризасызлыкларын (булган очракта) тикшерү актына терки.

үтәү вакыты: тикшерү актын почта аша юллаганнан соң һәм (яки) юридик затның, шәхси эшкуарның ризасызлыкларын алганнан соң турыдан-туры;

12) тикшерү актында халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау (бүлеп бирү) өлкәсендәге законнарның бозылу фактлары ачыкланганда, әлеге Административ регламентның 5.47 пунктында каралган административ гамәлләрне башкара.

5.25. Әгәр тапшырылган аңлатмаларны һәм документларны караганнан соң яки аңлатмалар булмаганда зарури таләпләрнең бозылу билгеләре билгеләнсә һәм урынга чыгып тикшерү уздыру өчен дәлилле нигезләү булганда, План әзерләү буенча вазыйфаи зат урынга чыгып тикшерү уздыру турында боерык проектын әзерли, аны имзалау өчен министрга (министр урынбасарына) җибәрә. Урынга чыгып тикшерү уздыру турында карарны министр (министр урынбасары) кабул итә. Урынга чыгып тикшерү үткәргәндә юридик заттан, шәхси эшкуардан документар тикшерү үткәрү барышында алар тарафыннан тапшырылган документларны һәм (яки) мәгълүматларны таләп итү тыела.

5.26. Уздырылган планлы документар тикшерү нәтиҗәләре буенча тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан карар кабул итү критериясе булып тикшерү барышында тапшырылган документларның һәм материалларның халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге законнарга туры килүе (туры килмәве) тора.

5.27. «Планлы документар тикшерү уздыру» административ процедурасының нәтиҗәсе булып халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге законнар бозылуның ачыкланган очракларын яки мондый очракларның булмавын теркәгән тикшерү акты тора, зарурлык булганда – урынга чыгып тикшерү уздыру турында боерык.

5.28. «Планлы документар тикшерү уздыру» административ процедурасын үтәү нәтиҗәсе тикшерү актында, тикшерүләрнең бердәм реестрында, Министрлыкның рәсми сайтында электрон формада теркәлә;

«Планлы документар тикшерү уздыру» административ процедурасын үтәү срогы – әлеге Административ регламентның 2.12 пунктына ярашлы рәвештә.

## «ПЛАННАН ТЫШ УРЫНГА ЧЫГЫП ҺӘМ ПЛАННАН ТЫШ ДОКУМЕНТАР ТИКШЕРҮЛӘР УЗДЫРУНЫ ӘЗЕРЛӘҮ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.29. «Планнан тыш урынга чыгып һәм планнан тыш документар тикшерүләр уздыруны әзерләү» административ процедурасын башлап җибәрү өчен әлеге Административ регламентның 2.18 пунктында күрсәтелгән очраклар нигез булып тора.

5.30. Министр (министр урынбасары) тикшерү уздыру турында карар кабул итә һәм юридик затка, шәхси эшкуарга тикшерү уздыру өчен Министрлыкның вазыйфаи затлары исәбеннән җаваплы башкаручыны (җаваплы башкаручыларны) (алга таба – тикшерү уздыруны әзерләүгә вәкаләтле вазыйфаи зат) билгели.

үтәү вакыты: планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигезләр барлыкка килгән

көннән башлап бер эш көне эчендә.

5.31. Тикшерү уздыруны әзерләүгә вәкаләтле вазыйфаи зат түбәндәге административ гамәлләрне башкара:

1) әлеге Административ регламентның 2.18 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән планнан тыш тикшерү уздыру нигезләре килеп туган очракта – әлеге Административ регламентның 2.19-2.23 пунктларында бәян ителгән таләпләргә ярашлы гамәлләрне:

а) мөрәҗәгать итүче затны ачыклау буенча гакыллы чаралар күрә;

б) шуңа охшаш, элегрәк килгән мөрәҗәгатьләрнең һәм гаризаларның нәтиҗәләрен, мәгълүматларны, шулай ук тиешле юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата элегрәк үткәрелгән контрольлек чараларының нәтиҗәләрен карап тикшерә;

в) килгән мәгълүматка башлангыч тикшерүне үткәрә;

г) зарурлык булганда юридик зат, шәхси эшкуар белән хезмәттәшлек итмичә генә һәм күрсәтелгән затларга мәгълүмат тапшыру һәм Министрлык таләпләрен үтәү буенча бурычлар йөкләмичә генә гамәлгә ашырыла торган контрольлек чараларын үткәрә;

д) әлеге Административ регламентның 2.18 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләрдә планнан тыш тикшерү билгеләү турында дәлилле йогынты актын әзерли;

2) әлеге Административ регламентның 5.12 пунктында күрсәтелгән таләпләрне үтәп, тикшерү уздыру турында боерык (күрсәтмә) проектын әзерли (тикшерү уздыру турында боерыкның (күрәтмәнең) бертип формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган).

үтәү вакыты: министр (министр урынбасары) тарафыннан тикшерү уздыру турында карар кабул ителгәннән соң ике эш көненнән артык түгел;

3) министрның (министр урынбасарының), тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи затны билгеләп, тикшерү уздыру турында боерыкка (күрсәтмәгә) кул куюын тәэмин итә;

үтәү вакыты: ике эш көненнән артык түгел;

4) әлеге Административ регламентның 2.18 пунктының 2 пунктчасындагы «а» һәм «б» пунктчаларында күрсәтелгән нигезләр буенча планнан тыш урынга чыгып тикшерү әзерләгәндә:

- планнан тыш тикшерү уздыруны килештерү турында гариза әзерли һәм юридик затның, шәхси эшкуарның эшчәнлеге гамәлгә ашырылган урын буенча прокуратура органына тапшыра (планнан тыш урынга чыгып тикшерүне прокуратура органы белән килештерү турында гаризаның бертип формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган) яисә аны кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы итеп җибәрә яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында җибәрә, тикшерү уздыру турында боерык (күрсәтмә) һәм аны уздыру нигезе булып хезмәт иткән белешмәләрне үз эченә алган документларның күчермәләрен терки;

үтәү вакыты: тикшерү уздыру турында боерык (күрсәтмә) имзаланган көнне;

- прокуратура органыннан планнан тыш урынга чыгып тикшерү уздыруны килештерү турында карар ала;

5) юридик зат җитәкчесенә, шәхси эшкуарга урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәреләчәге турында, әлеге Административ регламентның 2.18 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләрдә үткәрелә торган урынга чыгып планнан тыш тикшерүдән кала, теләсә нинди үтемле ысул белән, шул исәптән көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм юридик затның, шәхси эшкуарның электрон почта адресына җибәрелгән электрон документ рәвешендә хәбәр җибәрә, әгәр мондый адрес тиешенчә юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында булса, яисә юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан Министрлыкка элегрәк тапшырылган булса.

үтәү вакыты: юридик затка, шәхси эшкуарга хәбәр итү – тикшерүне үткәрә башларга кимендә егерме дүрт сәгать калганчы.

5.32. Тикшерү уздыруны әзерләүгә вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан планнан тыш урынга чыгып һәм планнан тыш документар тикшерүләр уздыруны әзерләү буенча карар кабул итү критериясе булып әлеге Административ регламентның 2.18 пунктында күрсәтелгән очракларның булуы тора.

5.33. «Планнан тыш урынга чыгып һәм планнан тыш документар тикшерүләр уздыруны әзерләү» административ процедурасының нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

тикшерү уздыру өчен тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи затны билгеләү;

тикшерү уздыру турында боерык (күрсәтмә);

прокуратура органыннан планнан тыш урынга чыгып тикшерү уздыруны килештерү турында карар алу;

юридик зат, шәхси эшкуар адресына тикшерү уздыру турында хәбәр җибәрү.

5.34. «Планнан тыш урынга чыгып һәм планнан тыш документар тикшерүләр уздыруны планлаштыру һәм әзерләү» административ процедурасын үтәү нәтиҗәләрен теркәү Министрлыкта эш башкаруны алып бару кагыйдәләре нигезендә, билгеләнгән тәртиптә әлеге Административ регламентның 5.33 пунктында күрсәтелгән хәбәр, боерык (күрсәтмә) күчермәләрен исәпкә алу һәм эш материалларында саклау, шулай ук әлеге документларның белешмәләрен аерым электрон формада саклау юлы белән гамәлгә ашырыла.

## «УРЫНГА ЧЫГЫП ПЛАННАН ТЫШ ТИКШЕРҮ УЗДЫРУ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.35. «Урынга чыгып планнан тыш тикшерү уздыру» администартив процедурасын башлап җибәрү өчен әлеге Административ регламентның 2.18 пунктында күрсәтелгән очракларның килеп җитүе, мондый эш бирүченең эшчәнлеге гамәлгә ашырылган урын буенча прокуратура органы белән тикшерү уздыруны килештерү, «Планнан тыш урынга чыгып һәм планнан тыш документар тикшерүләр уздыруны әзерләү» административ процедурасының тәмамлануы нигез булып хезмәт итә.

5.36. Тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи зат түбәндәге административ

гамәлләрне башкара:

1) әлеге Административ регламентның 5.18 пунктының 1 пунктчасында каралган административ гамәлләрне башкара;

2) документларда булган, тикшерүнең максатларына, бурычларына һәм предметына бәйле белешмәләрне өйрәнә һәм нигезләр булуга карап түбәндәгеләрне тикшерә:

а) эш бирүченең зарури таләпләрнең ачыкланган бозуларын һәм (яки) Татарстан Республикасы хокукый актларында билгеләнгән таләпләр бозылуны бетерү турында элегрәк бирелгән күрсәтмәне үтәвен (әгәр планнан тыш тикшерү уздыру нигезе булып юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан зарури таләпләрнең ачыкланган бозуларын бетерүе турында күрсәтмәне үтәү срогының узып китүе торса, мондый тикшерүнең предметы булып фәкать Министрлыктан бирелгән күрсәтмә үтәлешен тикшерү генә тора ала);

б) гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерелүне чикләү, мондый зыян салыну нәтиҗәләрен бетерү буенча чаралар уздырылуын;

в) Министрлыкка килгән, шул исәптән шәхси эшкуарлардан, юридик затлардан, мөрәҗәгатьләрдә һәм гаризаларда, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан гражданнарның хокуклары бозылуы (билгеләнгән квота чикләрендә инвалидны эшкә алудан нигезсез баш тарту) турында мәгълүматларда бәян ителгән фактларны;

г) прокуратура органнарына килгән материалларда һәм мөрәҗәгатьләрдә бәян ителгән фактларны;

3) әлеге Административ регламентның 5.18 пунктының 4-14 пунктчаларында каралган административ гамәлләрне башкара;

4) тикшерү акты күчермәсен планнан тыш урынга чыгып тикшерү уздыруны килештерү турында карар кабул иткән прокуратура органына аңа имзан салынган көннән башлап 5 эш көне эчендә җибәрә;

5) тикшерү актында халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау (бүлеп бирү) өлкәсендәге законнарның бозылу фактлары ачыкланганда, әлеге Административ регламентның 5.47 пунктында каралган административ гамәлләрне башкара.

5.37. Тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан планнан тыш урынга чыгып уздырылган тикшерү нәтиҗәләре буенча карар кабул итү критериясе булып тикшерү барышында тапшырылган документларның һәм материалларның халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге законнарга туры килүе (туры килмәве) тора.

5.38. «Урынга чыгып планнан тыш тикшерү уздыру» административ процедурасының нәтиҗәсе булып халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннары булдыру (бүлеп бирү) өлкәсендәге законнар бозылуның ачыкланган очракларын яки мондый очракларның булмавын теркәгән тикшерү акты тора.

5.39. «Урынга чыгып планнан тыш тикшерү уздыру» административ процедурасын үтәү нәтиҗәсе тикшерү актында, тикшерүләрнең бердәм реестрында, Министрлыкның рәсми сайтында электрон формада теркәлә;

«Урынга чыгып планнан тыш тикшерү уздыру» административ процедурасын үтәү срогы – әлеге Административ регламентның 2.12 пунктына ярашлы рәвештә.

5.40. Әгәр шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең яки башка вазыйфаи затының булмый торуына бәйле рәвештә, яисә юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан эшчәнлекнең фактта башкарылмавына бәйле рәвештә, шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең яки башка вазыйфаи затының бүтән төрле, тикшерүне үткәрү мөмкинлеген юкка чыгаручы гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында планнан тыш урынга чыгып тикшерүне үткәрү мөмкин булмаса, тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи зат, әлеге Административ регламентның 5.22 пунктына туры китереп, гамәлләр башкара.

## «ПЛАННАН ТЫШ ДОКУМЕНТАР ТИКШЕРҮ УЗДЫРУ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.41. «Планнан тыш документар тикшерү уздыру» администартив процедурасын башлап җибәрү өчен әлеге Административ регламентның 2.18 пунктында күрсәтелгән очракларның килеп җитүе һәм «Планнан тыш урынга чыгып һәм планнан тыш документар тикшерүләр уздыруны әзерләү» административ процедурасының тәмамлануы нигез булып хезмәт итә.

5.42. Тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи зат түбәндәге административ гамәлләрне башкара:

1) әлеге Административ регламентның 5.36 пунктының 2 пунктчасында каралган административ гамәлләрне;

2) әлеге Административ регламентның 5.24 пунктының 2, 5-11 пунктчаларында каралган административ гамәлләрне;

3) тикшерү актында халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау (бүлеп бирү) өлкәсендәге законнарның бозылу фактлары ачыкланганда, әлеге Административ регламентның 5.47 пунктында каралган административ гамәлләрне.

5.43. Уздырылган планнан тыш документар тикшерү нәтиҗәләре буенча тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан карар кабул итү критериясе булып тикшерү барышында тапшырылган документларның һәм материалларның халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге законнарга туры килүе (туры килмәве) тора.

5.44. «Планнан тыш документар тикшерү уздыру» административ процедурасының нәтиҗәсе булып халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге законнар бозылуның ачыкланган очракларын яки мондый очракларның булмавын теркәгән тикшерү акты тора, зарурлык булганда – урынга чыгып тикшерү уздыру турында боерык.

5.45. «Планнан тыш документар тикшерү уздыру» административ процедурасын үтәү нәтиҗәсе тикшерү актында, тикшерүләрнең бердәм реестрында, шулай ук Министрлыкның рәсми сайтында электрон формада теркәлә.

«Планнан тыш документар тикшерү уздыру» административ процедурасын үтәү срогы – әлеге Административ регламентның 2.12 пунктына ярашлы рәвештә.

## «АЧЫКЛАНГАН БОЗУЛАРНЫҢ НӘТИҖӘСЕН ЧИКЛӘҮ ҺӘМ (ЯКИ) БЕТЕРҮ БУЕНЧА РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ ЗАКОННАРЫНДА КАРАЛГАН ЧАРАЛАРНЫ КҮРҮ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.46. Административ процедураны башлап җибәрү өчен халыкны эшкә урнаштыруга булышлык күрсәтү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге законнарның тикшерү актында чагылдырылган бозу фактлары нигез булып тора.

5.47. Тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи зат түбәндәге административ гамәлләрне башкара:

1) зарури таләпләрнең ачыкланган бозуларын бетерү турында һәм (яки) кешеләрнең гомеренә, сәламәтлегенеә зыян китерелүне чикләү буенча чаралар, шулай ук федераль законнарда каралган башка чараларны уздыру турында үтәү өчен мәҗбүри күрсәтмәне әзерли һәм бирә (үрнәк рәвеше әлеге Административ регламентның 6 нчы кушымтасында китерелде).

үтәү вакыты: тикшерү тәмамланганнан соң турыдан-туры тикшерү актын төзү белән бер үк вакытта;

2) юридик зат җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә әлеге Административ регламентның 5.18 пунктындагы 11, 12 пунктчаларына ярашлы рәвештә тикшерү акты белән бергә күрсәтмәне кул куйдыртып тапшыра;

3) ачыкланган бозуларны бетерү, аларны кисәтү, гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә ихтимал зыянны булдырмый калуны тикшерүдә тоту буенча чаралар, шулай ук ачыкланган бозуларга юл куйган затларны җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрә;

үтәү вакыты: кисәтү, күрсәтелгән очракларны булдырмый калу – бозулар ачыкланганнан соң турыдан-туры; бетерүне тикшерүдә тоту – бетерү чоры барышында.

5.48. Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзеүгә вәкаләтле вазыйфаи зат түбәндәге административ гамәлләрне башкара:

1) Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 5.42 статьясының 1 өлешендә каралган административ хокук бозу вакыйгасы булуына күрсәтә торган җитәрлек күләмдә белешмәләрнең булуы предметына тапшырылган материалларны карый, үзләренә карата Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 5.42 статьясының 1 өлеше нигезендә административ хокук бозу турында эш кузгатыла торган юридик затка, шәхси эшкуарга (кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы белән яки факсимиль элемтә чараларыннан яки электрон почтадан файдаланып) административ хокук бозу вакыйгасының булуы һәм датасы турында хәбәр итүне тәэмин итә;

2) җитәрлек дәрәҗәдә белешмәләр булганда, юридик зат җитәкчесенә, шәхси эшкуарга административ хокук бозу турында беркетмә төзү урыны турында хәбәр итүне тәэмин итә;

үтәү вакыты: социаль яклау идарәсе (бүлеге) әлеге Административ регламентның 5.47 пунктының 2 пунктчасында билгеләнгән документларны һәм материалларны тапшырган көннән башлап өч эш көне узганчы;

3) үзенә карата административ хокук бозу турында эш кузгатыла торган шәхси эшкуарга яки юридик зат җитәкчесенә җибәрелгән хәбәрдә күрсәтелгән, административ хокук бозу турында беркетмә төзү датасына туры килгән көнне, әгәр эшнең шартларын өстәмә ачыклау яки шәхси эшкуар турында белешмәләрне яки юридик зат җитәкчесе турында мәгълүматларны тәгаенләү таләп ителмәсә, Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 5.42 статьясының 1 өлешендә каралган административ хокук бозу турында беркетмәне төзи. Административ хокук бозу турында беркетмә төзелгәндә үзләренә карата административ хокук бозу турында эш кузгатылган эшкуарга яки юридик затка, шулай ук эш башкарудагы башка катнашучыларга аларның Административ хокук бозулар турында РФ кодексында каралган хокуклары һәм бурычлары турында аңлатыла, бу хакта беркетмәдә язу теркәлә. Үзләренә карата административ хокук бозу турында эш кузгатылган шәхси эшкуарга яки юридик зат җитәкчесенә административ хокук бозу турында беркетмә белән танышып чыгу мөмкинлеге тудырылырга тиеш. Күрсәтелгән затлар беркетмә эчтәлеге буенча аңлатмалар һәм кисәтүләр җиткерергә хокуклы, алар беркетмәгә теркәлә. Шәсхи эшкуар яки юридик зат җитәкчесе административ хокук бозу турында беркетмәне имзалаудан баш тарткан очракта, беркетмәгә тиешле язуны терки. Административ хокук бозу турында беркетмә күчермәсе үзенә карата төзелгән затка кичекмәстән тапшырыла.

Үзләренә карата административ хокук бозу турында эш буенча производство алып барыла торган эшкуар яки юридик зат җитәкчесе килмәгәндә, әгәр аларга билгеләнгән тәртиптә хәбәр ителгән булса, административ хокук бозу турында беркетмә алар юклыгында төзелә;

4) эшкуарга яки юридик зат җитәкчесенә административ хокук бозу турында беркетмә күчермәсен җибәрүне (кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы белән, яки факсимиль элемтә чараларыннан файдаланып йә электрон почта буенча) тәэмин итә, – административ хокук бозу турында беркетмә төзү өчен килмәгән очракта 3 эш көне эчендә;

үтәү вакыты: беркетмә төзелгән көннән башлап өч эш көненнән артык түгел.

5) административ хокук бозу турында беркетмәнең административ хокук бозу турында эшне карау өчен гомуми юрисдикция судына тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы итеп җибәрелүен тәэмин итә.

үтәү вакыты: беркетмә төзелгән көннән башлап өч тәүлектән артык түгел;

6) үзенә карата административ хокук бозу турында эш кузгатылган шәхси эшкуардан яки юридик зат җитәкчесеннән беркетмәгә ризасызлыклар килгән очракта, административ хокук бозу турында беркетмә эчтәлеге буенча аңлатмаларның яки кисәтүләрнең билгеләнгән тәртиптә административ хокук бозу турында эш карала торган гомуми юрисдикция судына җибәрелүен тәэмин итә.

үтәү вакыты: административ хокук бозу турында беркетмә эчтәлеге буенча аңлатмалар яки кисәтүләр килгән көннән башлап өч эш көненнән артык түгел;

7) административ хокук бозу турында беркетмә күчермәсен тикшерү

материалларына терки.

